ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ГАЙТЭН АВЫЛЫ СОВЕТЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН
СОВЕТ ГАЙТАНКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

423014, РТ, Нурлатский район, с. Гайтанкино, ул. Центральная, дом 1,
Тел. 8 (84345) 3-98-01

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«23» октябрь 2020 № 2

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлегенең Кәкре Атау авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гәйтән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2020 елның 10 ноябрендә 13 сәгать 00 минутка Гайтән авыл җирлеге Кәкре Атау авылында Үзәк тыкрык, 2нче йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кәкре Атау авылында Үзәк урамы буенча 1-68нче йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2020 елның 11 ноябрендә 18 сәгать 00 минутка Гайтән авыл җирлеге Кәкре Атау авылында Үзәк тыкрык, 2нче йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кәкре Атау авылында Үзәк урамы буенча 69-124нче йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. 2020 елның 12 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Гайтән авыл җирлеге Кәкре Атау авылында Үзәк тыкрык, 2нче йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кәкре Атау авылында Кыр урамы буенча 1-59нчы йортлардан, Үзәк тыкрыгы буенча 1-14нче йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының өченче этабын уздыруны билгеләргә.

4. Гражданнар җыенын уздыру өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлүне сайлау тәртибен территориаль буенча башкарырга.

5. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эше Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

6. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гайтән авыл җирлеге Кәкре Атау авылында теркәлгән яшәү урыны буенча торучы балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидлардан тыш, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2021 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

Кәкре Атау торак пунктында су белән тәэмин итү чыганагын норматив таләпләр белән тәэмин итү буенча эшләр үткәрү.

Кәкре Атау торак пунктында янгын сүндерү гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру.

Кәкре Атау торак пунктында ял паркын төзекләндерү.

« РИЗА» «КАРШЫ»

7. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (игълан итәргә) һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/rus/nurlat_poselenia.htm, бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кәкре Атау авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга

8. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы<br>
Нурлат муниципаль районы<br>
Гайтән авыл җирлеге башлыгы Н. В. Авдеева